## *УКУЧЫЛАР КАЛӘМ ТИБРӘТӘ, ҺӨНӘРЛӘР ДӨНЬЯСЫНДА ЙӨЗӘ*

*Мөслим гимназиясе укучылары иҗаты*

### Минем булачак һөнәрем

Мин киләчәктә теш табибы булырга телим. Стоматология – тешләр, авыз куышлыгы белән бәйле медицина тармагы. Әлеге һөнәр кешеләрнең сәламәтлеген сакларга мөмкинлек бирә.

Теш табибы булуның күп өстенлекләре бар. Беренчедән, алар кешеләргә тешләрен дәвалап, сәламәтлекләрен ныгытырга ярдәм итәләр. Күп кеше теш авыртуы белән газаплана, теш табибы аларга ярдәм күрсәтүчеләрдән беренче булып тора.

Икенчедән, стоматология – даими үсештә булган фән. Яңа технологияләр, материаллар һәрвакыт барлыкка килә. Теш табибы буларак, мин гел үз белемемне арттырырга һәм һөнәри үсештә булырга тырышачакмын. Бу миңа үз эшемне яхшырту һәм пациентларыма иң яхшы нәтиҗә күрсәтергә ярдәм итәчәк.

Өченчедән, теш табибы булып эшләү мине иҗади яктан да җәлеп итә. Тешләрне дәвалау гына түгел, аларнын формасының, төсенең һәм гомумән, авыз куышлыгының матурлыгы игътибарга алынырга тиеш.

Теш табибы минем өчен бик мөһим һәм җаваплы һөнәр. Киләчәктә теш табибы булу хыялын тормышка ашыру өчен мин медицина университетына укырга керергә телим. Минем хыялым – яхшы табиб булып, кешеләргә ярдәм кулы сузу һәм аларның елмаюын күрү!

Галимова Айназ,
8 б сыныфы укучысы

*******

Минем хыялым – биюче булу. Бию – тормышның бер өлеше, ул миңа шатлык, ирек һәм иҗади мөмкинлекләр китерә. Биюче булу – үз – үзеңне белдерү, хисләреңне һәм эмоцияләреңне башкаларга җиткерү.

Бию белән кечкенәдән кызыксына башладым, һәрвакыт телевизордан бию программаларын карарга яраттым. Биючеләрнең хәрәкәтләре, аларның энергиясе мине әсир итте. Алар кебек матур һәм синхрон рәвештә биисем килә.

Бию – ул физик активлык кына түгел, ул шулай ук иҗат. Минем өчен бию – үземне иректә тоту, хисләремне белдерү һәм башкалар белән уртакашу. Бию аша мин дөньяны башкача күрә алам. Ул миңа бәхет, тынычлык һәм иҗади энергия бирә, бу хыялымны чынга ашырырга тырышам!

Мадьярова Мәрьям,

8б сыйныфы укучысы

***

Минем булачак һөнәрем – тәрбияче. Кем булырга теләвем турында озак уйладым, әмма нәтиҗәдә балалар белән эшләргә теләвемне аңладым.

Балаларны яратам, үземнең энеләрем һәм сеңлеләрем бар, аларны карыйм. Миңа балаларга ни өчен кулларны юарга яки киемнәрне ничек kиярга кирәклеген, ни өчен уенчыкларны плитәгә куярга яки эшләрдән качарга ярамавын аңлату ошый. Укучылар боларның барысын да белә инде, ә менә кечкенәләр юк, шуңа күрә, нәкъ менә алар белән эшләргә телим.

Тәрбияче эше – балалар белән уен уйнау гына түгел, аның үз авырлыклары бар. Мәсәлән, ата – аналар белән тату яшәргә өйрәнергә, яки спектакльләр куярга, яки бик игътибарлы булырга кирәк, чөнки өч баланы түгел, ә утыз баланы тәрбияләргә туры килә.

Тәрбияче һөнәре ошый һәм мин барысын да булдырырмын дип өметләнәм.

Зулунова Ирода,

8в сыйныфы укучысы.

***

Мин киләчәктә юрист булырга телим. Юрист – мөһим һәм җаваплы эш. Аның төп бурычлары: законнарны саклау, кешеләрнең хокукларын яклау һәм гади гражданнарга законнар белән танышу ярдәме күрсәтү. Юристлар төрле учреждениеләрдә, судларда эшли алалар.

Киләчәгем турында күп уйлыйм һәм шундый югарылыктагы белгечкә әверелергә омтылам. Юридик өлкәдәге белемнәр миңа кеше хокукларына ихтирам белән карарга, законнарны өйрәнергә һәм җәмгыяттәге хәл – вакыйгаларга дөрес бәяләмә бирергә ярдәм итәчәкләр.

Кашапов Азамат,

8б сыйныфы укучысы

***

Яраткан һөнәрем – дизайнер. Балачактан ук мине матурлык, гармония һәм тәртип белән бәйле бөтен нәрсә җәлеп итте. Мин рәсем ясарга, гадәти әйберләрне ничек үзгәртергә мөмкин булуы турында фантазияләргә яратам. Нindидер яңа һәм матурлык булдыруга омтылуда мин үземнең булачак һөнәремне күрдем.

Дизайнер – ул рәсемнәр ясый торган кеше генә түгел. Ул чишелешләр эзләүче, идеяләрне тормышка ашыручы иҗади тикшеренүче. Дизайнерның эше һәрвакытта да җиңел түгел. Заказ бирүченең ихтыяҗларын ишетә һәм аңлый белү, шул ук идеяләреңә

һәм иҗади күзаллауларыңа тугры калу мөһим. Һәр проект – яңа чакыру, үз сәләтеңне күрсәтү һәм нindидер яңалыкка өйрәнү мөмкинлеге ул.

Ахырда, дизайнер һөнәре – эш кенә түгел, бу яшәү рәвеше, матурлыкка һәвәслек һәм камиллеккә омтылыш. Бу үз идеяләреңне чынбарлыкка ашыру һәм нинидер яңалык булдыру мөмкинлеге. Нәкъ менә шуңа күрә мин бу һөнәрне бик яратам һәм аны тормышка ашыра алуымны көтәм.

Кашапова Энҗе,<br>8а сыйныфы укучысы

***

Һәрберебез бала чактан ук булачак һөнәре турында хыяллана. Һөнәр – ул кешенең яраткан шөгыле. Кеше үзенең һөнәрен ератса гына, аның чын остасы була ала, зур уңышларга ирешә. Үзенә туры килгән һөнәрне дөрес сайлау кеше язмышында зур роль уйный. Кешеләргә дөрес һөнәрне сайлар өчен укытучы канат куя. Ул тәрбияли, укыта, һәркемне кеше итәргә омтыла.

Минем күңелемә табиб һөнәре хуш килә. Табиб булу уе мидә күптән туган иде. Табиб иң борынгы һөнәрләрнең берсе. Табиб булып эшләү кызыклы гына түгел, ә авыр да, җаваплы да.

Табиб үзе дә сәламәт булырга тиеш. Табиб авыруларны дару белән генә түгел, ә җылы карашы белән дә дәвалый. Табиб ул – кешеләргә бәхет бирүче. Табибка ышану – ул дәваның ярты юлы.

Әлегә мин мәктәптә укыйм. Барлык фәннәрне дә тырышып өйрәнәм. Мәктәптә алган белемнәрне киләчәк һөнәремә кирәк булыр дип уйлыйм.

Сираев Рөстәм,<br>8а сыйныфы укучысы

***

Һәр кешенең яраткан һөнәре була. Кемдер балалар ярата, алар тәрбияче, укытучы булалар. Кемдер кешеләр дәваларга тели, ул табиб һөнәрен сайлый.

Мин, бәлки, шофер һөнәрен сайлармын. Минем олы йөк машинасын йөртәсе килә. Ул машиналар илнең бер ноктасыннан, икенче ноктасына йөк ташыйлар, төрле Республикалардан үтәләр.

Ә шофер күпме яңа җирләр белән таныша. Ул машиналар зур булса да, идарә итәргә бик җайлы һәм көчле. Аларның кабиналарында кондиционер, хәтта йокы урыны бар.

Һәр һөнәрнең яхшы яклары булган кебек, авырлары да була. Шул авырлыкларга түзеп, аларны җиңеп, тырышып эшләсәң, уңышка ирешәсең.

Сабитов Динар,

8б сыйныфы укучысы

***

Балачактан бирле мин укытучыларыма сокланам. Алар миңа сабырлык, акыл һәм үз эшеңә тугрылык үрнәге булып торалар. Минем укытучым Гөлшат Марсовна миңа фикеләү сәләтен, тойгы хисләрен белдерү никадәр мөһим икәнен аңлата алды. Ул миңа матурлыкны күрергә һәм сәнгатьне бәяләргә өйрәтте.

Мин бу һөнәр күпме хезмәт, сабырлык һәм балаларга мәхәббәт таләп иткәнен аңлыйм. Чөнки минем әнием дә укытучы булып эшли.

Укытучының максаты – укучыларга белем генә бирү түгел, куелган максатларга ирешергә өйрәтү дә. Минем дә әнием, укытучым кебек балаларга белем бирәсе, аларда үземә карата ышаныч тудырасым килә. Чөнки җәмгыятьнең киләчәге булачак укытучыларга бәйле.

Хаҗиева Гүзәл,

8в сыйныф укучысы

***

Кечкенә вакытта мин һәрвакыт доктор булырга теләдем, ләкин әни белән беренче тапкыр хастаханәгә укол ясатырга баргач, бу һөнәрнең рәхимсез булуына инандым. Минем теләкләрем һәм башка һөнәргә тартылуым елдан – ел үзгәрә барды, әле актриса, әле пешекче булырга теләдем.

Ләкин бит актриса булу өчен яхшы хәтер һәм камералардан курыкмаска кирәк, ә бу сыйфатлар, кызганычка каршы, булмады. Ә бит мин һәрвакыт уйчан булам һәм болытларда очам, шуңа күрә барысын да онытам, игътибарсыз булгалыйм, бу хәтерем начар дигән сүз түгел.

Актриса була алам, ләкин барыбер актриса икенче планга китә. Пешекче булу да җиңел эш түгел, сабыр һәм хезмәт сөючән булырга кирәк. Башкалар синең ризыкларыңны сынап карасалар, пешекчегә тәнкыйтьтән курыкмаска кирәк.

Шуңа күр, әти – әнием үрнәгенә иярермен. Мин бит, гаиләм кебек, хайваннарны яратам, тик сез уйлаганча, ветеринар булмаячакмын. Өйрәтүче булырга телим!

Зәкиева Әминә,

8в сыйныф укучысы

***

Мин интерьер дизайнеры булырга телим, чөнки бу иҗади һәм кызыклы һөнәр, кешеләрнең өйләрен бизәргә, яшәр өчен акча эшләргә мөмкинлек бирә. Компьютер

программаларын үзләштереп, институтны тәмамлап,  яхшы компаниягә эшкә урнашам яки үз студиямне булдырырга да була.

Интерьер дизайны – ул пропорцияләр, колористика һәм моданың кагыйдәләренә буйсынучы сәнгать. Бу уңышлы бизнес, маркетинг, психология һәм төзелеш технологияләрен белүне тәлап итә.

Дизайнер булып эшләгәндә, мин үземнең иҗади потанциалымны тормышка ашыра алачакмын, клиентларның – теләкләрен исәпкә алып һәм уникаль проектлар булдырып, оригиналь һәм матур интерьерлар уйлап таба алачакмын.

Фәхрәзиева Алинә,
8в сыйныф укучысы

***

Һәр кешенең тормышында һөнәр сайлау вакыты җитә. Бу җаваплы адым, аны һәркем үзе эшләргә тиеш. Мин, мәсәлән, юрист булырга телим. Җәмгыятьтә юристларның роле әһәмиятле, алардан күп очракта кеше тормышы да бәйле булырга мөмкин. Юрист белемле булырга, барлык законнарны белергә һәм даими камилләшергә, белемнәрен тулыландырырга тиеш.

Юрист һөнәре гаделсез вәзгыятьне ачыкларга, гаепсез кешеләргә ярдәм итәргә мөмкинлек бирә. Бу һөнәр куркыныч та булырга мөмкин, гаделлек артыннан кууда кешенең дошманнары барлыкка килергә мөмкин. Әмма кешеләргә ярдәм итү һәм дөньяны бераз гына булса да яхшырак итү теләге барлык куркуларны юкка чыгара.

Язмамны тәмамлап шуны әйтәсем килә: кыенлыклардан курыкмаска һәм куркуларыңа сине җиңәргә ирек бирмәскә кирәк. Һөнәр сайлаганда хаталар ясаудан куркырга кирәкми. Егерме беренче гасырда мөмкинлекләр шулкадәр күп, син теләсә кайсы һөнәргә укып, үзеңә ошаган белгечлек буенча эшли аласың.

Замалова Зәринә,
8в сыныфы укучысы